СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

05.09.2022 г. Агрыз № 19-4

**«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап органы рәисенә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2022 елның 25 февралендәге 15-5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 86 статьясындагы 4 пункты, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Дәүләт сере турында» 1993 елның 21 июлендәге 5485-I номерлы Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт серенә даими нигездә кертелгән гражданнарга һәм дәүләт серен яклау буенча структур бүлекчәләр хезмәткәрләренә социаль гарантияләр бирү турында» 2006 елның 18 сентябрендәге 573 номерлы карары, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 26 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»2018 елның 28 августындагы 182 номерлы карары, муниципаль норматив хокукый актны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары белән расланган норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру методикасының 3 пунктындагы «в» пунктчасына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Кушымта итеп бирелгән «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап органы

рәисенә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2022 елның 25 февралендәге 15-5 номерлы карарына үзгәрешләрне расларга.

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап органы рәисенә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2022 елның 25 февралендәге 15-5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2022 елның 21 апрелендәге 17-8 номерлы карарына кушымтаның 1, 2 пунктларын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанс буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе А.Р. Вәлиев

Татарстан Республикасы
Әгерже муниципаль районы Советының
25.02.2022 № 15-5 карары белән расланган
(05.09.2022 № 19-4 карары редакциясендә)

**«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап органы рәисенә, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2022 елның 25 февралендәге 15-5 номерлы карарына үзгәрешләр**

1. «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап органы рәисенә, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2022 елның 25 февралендәге 15-5 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Советының 2022 елның 25 февралендәге 15-5 номерлы карарына 14 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итеп (кушымта итеп бирелә), үзгәрешләр кертергә.

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы Советының
25.02.2022 № 15-5 карарына 14 нче кушымта
( 05.09 2022 № 19-4 карары редакциясендә)

**Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык процент өстәмәләр күләме**

1. Муниципаль хезмәттә дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләр белән эшләгән өчен вазыйфа окладына айлык процент өстәмә әлеге муниципаль хезмәткәрләрнең законлы рәвештә документлаштырылган үтемлелегенә бәйле рәвештә түләнә.

2. Муниципаль хезмәттә дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләр белән эшләгән өчен айлык хезмәт хакына өстәмә түбәндәге күләмдә түләнә:

| Айлык процент өстәмә | Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләү өчен өстәмәләр күләме (вазыйфаи окладка карата %ларда) |
|---|---|
| «Аеруча мөһим» серлелек дәрәҗәсенә ия булган белешмәләр белән эшләгән өчен | 12,2-18,3 |
| Серлелек дәрәҗәсе "бөтенләй яшерен" булган мәгълүматлар белән эшләгән өчен | 7,4-12,2 |
| Түбәндәгеләр өчен рөхсәт рәсмиләштергәндә серлелек дәрәҗәсе "яшерен" булган мәгълүматлар белән эшләгән өчен: | |
| - тикшерү чараларын үткәреп | 2,5-3,7 |
| - тикшерү чараларын үткәрмичә | 1,3-2,5 |
| Дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләрдә эш стажы өчен: | |
| - 1 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| - 5 елдан 10 елга кадәр | 3,7 |
| - 10 елдан һәм күбрәк | 4,9 |